# Менә шундый ул — Питрау



Питрауның алыштыргысыз алып баручылары.

Кояш рәхәтләнеп кыздыра. Күләгәдә дә утызга якын эсселек. Берни уйламыйча су буенда гына ятарлык көн. Юк шул, 14 июль көнне кичкә табан шәһәрдәшләребез Кама буена түгел, ә Җиңү паркына таба юнәлде.

Чаллы өчен Питрау ул шундый бәйрәм: аны керәшене дә, татары да, урысы, мордвасы, чуашы да яратып көтеп ала, җыелышып килә, рәхәтләнеп ял итә. Быел да менә унбишенче тапкыр инде бәйрәмне оештырып, алып баручыларның берсе — Раиса Дмитриевна Ипеева бер-берсен сагынышып килгән дуслар, туганнар очрашып серләшсен өченме, әллә бәйрәмнең төп өлеше башланганчы ук халыкны “кыздырып аласы” килепме, сәхнәгә гармунчы Петров Александрны чакырды. Һәм Җиңү паркының шушы почмагында гаҗәеп күңелле, гади, халыкчан тамаша башланып китте. Гармуннан агылган күңелле көйләр күпләрне, мәйдан уртасына алып чыгып, рәхәтләнеп биетте. Ул тынган арада, сәхнәдә яшь артистлар София белән Валерия Храмовалар, Алина Әхмәтшина чыгыш ясады. Аларны Марина Майорова, “Карендәшләр” керәшен-фольклор ансамбле коллективы алыштырды.

Керәшеннәрне котлап, алар белән бергәләп рәхәтләнеп ял итәргә шәһәрнең Башкарма комитеты рәисе урынбасары Х.Гәләветдинов, мәгариф бүлеге җитәкчесе Р.Хәлимов, “Чишмә” халыклар дуслыгы йорты директоры Ф.Белецкая, Милли җәмгыятьләр җитәкчеләре Л.Штейнберг, М.Чахоян, Ж.Карлович һ.б. килгән иде. Алар, керәшен халкын бәйрәмнәре белән котлап, гореф-гадәтләрнең буыннан-буынга күчеп килүенә чын күңелдән куануларын, киләчәктә дә бу традицияләрнең дәвам итәчәгенә ышануларын белдерделәр.

Шәһәрнең керәшен җәмгыяте рәисе Н.П.Ипеев та:

— Безнең Питрау республикабыз шәһәрләре арасында беренчеләрдән булып уздырыла башлады. Башка төбәкләрдә хәзер аны бездән күреп уздыралар. Ел буена сагынып сөйләрлек булсын, җырлап-биеп, рәхәтләнеп ял итик, — диде.

Ә җыр-биюгә, уен-көлкегә, төрле конкурсларга быелгы Питрау программасы бик бай булды. “Карендәшләр” ансамбле, җырчылар В.Мартемьянов, Д.Хуҗина, Л.Мортазина, Э.Анисимоваларның моңлы керәшен җырулары кич буена бәйрәмне бизәп торды. Шуның өстенә күрше Минзәлә районы Мәлкән авылыннан килгән Светлана Упаева җитәкчелегендәге “Айбагыр” балалар керәшен-фольклор ансамбле оста итеп керәшен җыруларын башкарып халыкны “аһ” иттерде.

Такмак әйтү, себерке бәйләү, чәчәкләрдән тәкыя, таҗ үрү, “Керәшен чибәре”, “Питрауның иң көчле ир-егете”, төрле бию конкурслары барысы да бик тә оешкан, кызыклы үтте. Уеннарда күпләр катнашып, бөтен мәйдан “болеть” итеп торды. Жюри чыгарган нәтиҗәләр дә бик дөрес иде. Питрау чибәре булып — Эльвина Анисимова, иң көчле егет итеп — Мәләкәстән Анатолий Никифоров танылды. Конкурсларда катнашкан һәркем төрледән-төрле бүләкләр алды.

Ләкин Питрауда халык бик тә яратып өлгергән “Моңлы Чаллы” җыр коллективы һәм аның җитәкчесе, Татарстанның атказанган артисты, җырчы-композитор Виталий Агапов катнашмаса, мөгаен, бәйрәмнең бер чите китек булыр иде. Менә унбиш елдан бирле инде Виталий Агапов белән Раиса Ипеева, алыштыргысыз алып баручылар булып, күп еллар Питрау бәйрәмен бөтен тирә-якны сокландырырлык итеп гөрләтәләр. Үзләренең җор телле лекләре, күп нәрсәдән мәгълүматлы булулары, урынлы гына “чәнечкеле” сүзләр куллanулары белән мәйданны гел үзләренә каратып торалар. Ә инде “Моңлы Чаллы” җыр коллективы чыгышларын халык бик тә ярата. Бу Питрауда да шулай булды. Иң кечкенә артистлар Виктор белән Владик Агаповларның әтиләре язган “Безнең гаилә” җыры белән башлап җибәрелгән зур концерт чаллылыларны рәхәтләндереп ял иттерде.

Быелгы Питрау күңелләрдә әле озак сакланыр. Анда булучылар, очрашып, “Сабантуй — 2006” гүзәле Ләйсән Сафинаның да үз кавемнарыннан булуын, инде 15 елдан бирле Питрау сәхнәләрендә катнашучы Райка Асанованы котлап, рәхмәт җиткерүләре турында да, бөтен мәйдан белән бергәләшеп яраткан җырчылары Раиса Тимофеевага сәлам юллап, исәнлек теләүләре турында да кат-кат сөйләрләр. Менә шундый шул ул — Питрау. Үзе сагындыра, үзе онытылмый.

Ә "Туганайлар" газетасы коллективы бу бәйрәмдә дә җиң сызганып керәшеннәрне газетага яздыру кебек изге эшне башкарды. Язылучылар арасында соңыннан призга алып килгән электр чәйнеген уйнатып, укучыбыз Р.Антонованы бәхетле дә иттек әле.

**Р.МИХАЙЛОВА.**



Мәлкәннән "Айбагыр" балалар керәшен фольклор ансамбле.